**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.12.2024 г.Казань № 241од

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул итүнең 2023 елның 8 ноябрендәге 160од номерлы боерык белән расланган тәртибенә (2024 елның 26 февралендәге 29од номерлы, 2024 елның 17 сентябрендәге 158од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктчада «хисаптан өземтәләрне» сүзләрен «белешмәләр» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы бюджетына бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын түләтү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;»;

4.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар , шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче физик затның вафат булуын таныклый торган яисә аны вафат булган дип игълан итү фактын раслый торган документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс производствосын тәмамлау яисә индивидуаль эшкуар булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче граждан мөлкәтен реализацияләүне тәмамлау турындагы суд актын, шулай ук физик зат - Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче тарафыннан аны бөлгенлеккә төшүче (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеген туктату турында Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс производствосын тәмамлау яисә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче граждан мөлкәтен реализацияләүне төгәлләү турында суд акты (Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

гражданинның судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлануы турында Банкротлык турындагы белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешманың ликвидацияләнүе сәбәпле эшчәнлеге туктатылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын үз эченә алган документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

штраф рәвешендә яки аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, суд акты нигезендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында акт яисә ярлыкау акты (Тәртипнең 2 пунктының 2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктларында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару производствосын тәмамлау турында суд приставы-башкаручының карары (Тәртипнең 2 пунктының 2.6, $2.6^1$ пунктчаларында күрсәтелгән очракларда, шулай ук Тәртипнең 2 пунктының 2.7 пунктында күрсәтелгән очракта);

бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле банкротлык турындагы эш буенча производствоны туктату турында гаризаны кире кайтару турында суд акты (Тәртипнең 2 пунктындагы $2.6^1$ пунктчасында күрсәтелгән очракта);

теркәүче орган карары буенча күрсәтелгән реестрдан юридик зат - Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүчене төшереп калдыру турында Юридик

затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.7 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турындагы карарларны (Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта).».

Министр Р.И. Заһидуллин